**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә Урожайная урамында теркәлгән гражданнарына үзара салым кертү турында

17.11.2023 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә Урожайная урамында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Урожайная урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, № 647 указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Урожайная урамындагы торак пунктында балалар уен мәйданчыгында койма кую (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
МБ башлыгы Р.Ә. Каримов